Без музей заллары буйлап йөрергә яратабыз. Музей үткән белән киләчәкне тоташтыручы күпер бит ул. Безнең "Әдәби мирас" музее турында сөйлисебез килә. Мондый музейны бүтән җирдә очратканыбыз юк . Ул безнең мәктәптә 2005 елда ачылды. Аның ачылу тарихы да бик кызык. "Шөгер төбәге- хәзинәләр чишмәсе",- дигән Җәмит Рәхимов. Безнең якның иң зур хәзинәсе- ул кешеләр.Элек-электән төбәгебез турында халык җырлар иҗат иткән, бәетләр сөйләгән. Бүген дә безнең якларда талантлы язучылар, шагыйрьләр, рәссамнәр, композиторлар яши.Аларның иҗаты бөтен республикага , хәтта чит төбәкләргә дә билгеле. Шул иҗатны хөрмәт итү максатыннан районыбыз администрациясе Шамил Бикчурин исемендәге премия булдырды. Безнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары үзләренең һәр дәресләрендә милли-региональ компонент итеп күренекле иҗатчыларның эшләрен кулланалар. Нәкъ менә укытучылар тәкъдиме белән "Әдәби мирас" музее ачыла да инде. Ш.Бикчурин премиясе лауреатлары белән очрашулар, эзләнү эшләре, кулъязмаларны барлау, саклау, яшь буынга җиткерү була аның максаты.

. "Әдәби мирас" музееның **бурычлары: бик киңкырлы. Аңа:**

- туган төбәгебез язучыларының мирасын, кулъязмаларын барлау, җыю,туплап, саклау;

- мәктәпнең "Әдәби мирас" музее экспонатларын төрле дәресләрдә, класстан тыш чараларда куллану;

— үз халкыңа, тарихыңа, гореф-гадәтләреңә, мәдәниятеңә карата кызыксыну уяту;

— үз халкың белән горурлану хисе тәрбияләү;

— милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын булдыру;

— укучыларда иҗат итү омтылышы уяту,ддигәннәр керә.

Музейны ачу өчен эзләнүчән, тынгы белмәс, искиткеч эшкә сәләтлеккә ия булган Галия Җәмил кызы Хәлимова зур тырышлык куйды. Шамил Бикчурин исмендәге премия лауреатларының тормышын, иҗатын,

кульъязмаларын , әсәрләренең язылу тарихын туплау буенча матералларны бөртекләп-бөртекләп җыйдык без. Музей материаллары, аның экспонатларын җыюда күбесе, татар теле һәм әдәбияты укытучылары,”Чишмә” иҗат берләшмәсе әгъзалары , укучылар катнаша. Укучылар, укытучылар һәм ата-аналарның бердәм тырышлыгы нәтиҗәсендә бик күп материаллар, экспонатлар җыела.

Музей... Монданәрсәгенәюк! Укучылармузейнытулыландырумаксатыннанәдипләрдән, рәссамнардан, сәнгать эшлеклеләреннән шәхсиәйберләрен, истәлекле хатларын,култамгалы китапларны , фотосурәтләрне, афишаларны, мактау кәгазьләрен , әсәрләрләрнең беренче нөхсәсе язылган кыймәтле язмаларны, һ.б.җыйганнар.

Музей эшчәнлегендәәсәрләрнең язылу тарихынөйрәнүгәзуригътибарбирелә. Укучылар өченмузейдаүткәрелгән класс сәгатьләребалаларгабай мәгълүматбирә, язучылык эшен аңларгаярдәмитә, төбәгебез әдәбиятына да кызыксынууята. Шөгер төбәгенең әдәби мирасын өйрәнүдә музейдасаклануч иске кульъязмалар, иске китаплар, фоторәсемнәр, шәхси хатларбелемһәмтәрбиябирүдәзурәһәмияткәия.

Безнең мәктәбебездә 2005 нче елда Шамил Бикчурин исемендәге премиягә лаек булган шәхесләребезгә багышланган “Әдәби мирас ”музее ачылды.

“Әдәби мирас” музеын ачу турында боерык №21/ОД 23 март 2005 нче ел .Бу музейны ачу яңа иҗади шәхесләр тудыра, укучыларның үзаңнарын киңәйтә һәм баланың иҗади сәләтен актырта.

15 ел дәвамында тупланган экспонатларның саны меңнән артты. Алар төрле бүлекләргә берләштерелгән.

<u>Тупланган экспонатлар:</u>

1.Без тарихта эзлебез

2.Татар халкының язу тарихы

3.Татар халкы моңнан яралган

4.Көйгә салынган күңел

5.Шәһәр халык театры

6.Ш.Бикчурин премиясе лауреатлары.

7. “Әдәби мирас” музееның ачылу тарихы

Мин сезнең игътибарыгызга. “Әдәби мирас” музееның ачылу тарихы “ дигән экспозиция буенча сәяхәт тәкъдим итәм